ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

~~16.05.2022~~ № ~~04-08/4711~~
На №_______________от _____________

Идарәче оешмалар җитәкчеләренә

Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларын җибәрү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законның 45 статьясы нигезендә контроль (күзәтчелек) органнары профилактика чараларын уздыралар, шул исәптән контрольдә тотыла торган затларга һәм кызыксынган башка затларга зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирәләр.

Мәгълүмат бирү максатыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе Сезгә торак-коммуналь хезмәтләргә түләү өчен күпфатирлы йортта урыннарның милекчеләренә квитанцияләр тарату турында мәгълүмат хаты җибәрә.

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары нигезендә идарәче оешма күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләренә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларын җибәрергә тиеш.

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгы) кәгазь квитанцияләр җибәрү мәсьәләсе буенча аңлатма бирде. Әлеге аңлатма белән АКОЕ берләшмәсенең 2022 елның 24 мартындагы № 1/24-03/22П мөрәҗәгатенә 2022 елның 25 апрелендәге № 18135-ОЛ/16 җавапта танышырга мөмкин.

Россия Төзелеш министрлыгы аңлатып узганча, «кәгазь квитанцияләр таратудан баш тарту мөмкинлеге, электрон сервислар ярдәмендә түләү документын бирүнең кирәкле тәртибен күрсәтү юлы белән, күпфатирлы йорт белән идарә итү килешүендә, шулай ук күпфатирлы йортта бина милекчесе карары буенча, коммуналь хезмәтләрне башкаручыга тиешле гариза юллау юлы белән каралырга мөмкин».

Шуңа бәйле рәвештә, Россия Төзелеш министрлыгы түбәндәгеләрне күрсәтә.

«Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре кәгазь квитанцияләрне җибәрүдән баш тарту турында тиешле карар кабул итәргә хокуклы», Төзелеш министрлыгы фикеренчә, бу хәл «биналарның милекчеләренең мәнфәгатьләрен һәм хокукларын үтәүне гарантияли». Шулай ук «Россия Төзелеш министрлыгы торак-коммуналь хезмәт

ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

күрсәтү өчен электрон рәвештә түләү документларына өстенлек бирүгә этәргеч ясау инициативасын хуплый» дип тә күрсәтелә.

Шуның белән берлектә, «Торак-коммуналь хуҗалык дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2014 елның 21 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 22 пункты нигезендә, дәүләт мәгълүмат системасында шул исәптән күпфатирлы йортларга, торак йортларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен куелган ресурслар исемлеге, аларның күләме, сыйфаты һәм бәясе турында мәгълүмат, шулай ук күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда биналарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына күрсәтелгән коммуналь хезмәтләр, аларның бәясен исәпләүнең кулланылган тәртибен күрсәтеп, шулай ук мондый бәяне исәпләү һәм мондый ресурсларны китерүгә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтүгә тиешле килешүләр дә урнаштырылырга тиеш.

Әлеге мәгълүматка нигезләнү һәм эштә куллану өчен, шулай ук әлеге нормаларны бозуга юл куймау максатларында җибәрәбез.

Җитәкче С.А.Крайнов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 19E42CB3CE2D8C8132379D304BF461D729083

Владелец: Крайнов Сергей Аркадьевич

Действителен с 24.01.2022 до 24.04.2023